Духовно-просветительская газета

Индекс 52381

**Табиб мөнбәре**

# Файдалы киңәшләр



## Тамак авырту һәм аны дәвалау

«Шугабул иман» китабында имам ал-Байхакый Васил бине әл-Әксага хәдис китерә. Бервакыт Пәйгамбәребез янына бер кеше тамак авыртуыннан зарланып килә. Аллаһының Илчесе аңа: «Сиңа Коръән укырга кирәк», — дип әйтә.

Аллаһының Китабын күп мәртәбә укыганнан соң, чирле кешегә тынычлык һәм рәхимлелек килә. Бөтен тәне тынычлана, аның һәрбер әгъзасы үз вазыйфасын камил рәвештә үти башлый. Аллаһының боеруы буенча тазалык һәм иминлек килә, Бөек һәм Кодрәтле Аллаһы аны дәвалый, һәрчак Коръән уку дәвамында бөтен сеңерләр, тавыш ярылары төзекләнә, җан тынычлана һәм аңардан чирләрне барлыкка китерә торган бөтен нәрсәләр юкка чыга. Чөнки игелек һәлакәтлелек белән сыеша алмый. Коръән аятьләреннән нәрсә яхшырак булырга мөмкин соң! Коръән буенча гамәл кыла торган, аны укый торган, Пәйгамбәребез күрсәткән юл белән тормыш корган колларына Коръән аятьләре — бәлзәм, шифа һәм шәфкатьлелек.

«Сахих»ларда бәян ителгәнчә, «сезнең өчен иң яхшы дәвалау чарасы — кан алдыру һәм диңгез ладаны; миндальсыман бизе авырткан балаларыгызның тамакларына бармаклар белән басып җәзаламагыз».

Хәдисләрдә имам Әхмәд сөйләгәнчә, Җәбир әйткән: «Пәйгамбәребез Гайшә янына килгәч, борыныннан кан агып торган малайны күргән. «Нәрсә булган аңа?» — дип сораган. Аңа: «Тамагы һәм башы авыртудан иза чигә», — дип җавап биргән. Балаларыгызны җәфаламагыз. Миндальсыман биз һәм башы авырткан баланың анасы диңгез ладанын (чиркәүләрдә аны сумаланы гыйбадәт кылганда хуш ис чыгару өчен дә төтәтәләр) ваклап-изеп су белән бутасын да, шуны баланың борынына тамызсын». Шулай эшләгәч, малай сәламәтләнгән».

Әбү Убайда әйткән: «Тонзиллит — канга бәйле тамак авыртуы». Тагын болай да әйтәләр: тонзиллит — аеруча яшүсмерләр җәфа чигә торган шеш. Ул колак белән тамак арасында барлыкка килә. Уылган ладан — яшүсмер организмында тупланган канлы лайладан торган тонзиллитка каршы нәтиҗәле чара. Диңгез ладаны миндальсыман бизгә элекке урынына җыелырга ярдәм итә. Бу чара башка авыруларга да сәламәтләнергә булыша. «Әл-Канун» авторы язганча, диңгез ладаны, йәмән ачуташы эремәсе һәм майоран орлыгы шулай ук бу авыруга каршы көрәшергә файдалы дару.

Хәдистә искә алынган диңгез ладаны шулай ук һинд алоэсы дип тә атала. Аксыл төстә, тәме баллы һәм башка файдалы үзлекләргә ия ул. Элек кешеләр тонзиллитны миндальсыман бизгә бармаклар яки башка әйбер белән баскалап дәваларга тырышканнар. Пәйгамбәр болай дәвалауны тыйган һәм тамак авыртуын җиңелрәк, файдалырак дәвалау ысулларын өйрәткән.

Уылган, кипкән гади һәм катлаулы дару борын аша кертелә. Бу чакта авыручы иңбашларын күтәреп аркасына ята, башы артка ташлана. Мондый торышта дару авырткан урынга җиңелрәк ирешә һәм авырттыра торган матдә төчкерә-төчкерә тизрәк чыга. Ихтыяҗ булганда шулай эшләнә. Әбү Давыт Пәйгамбәрнең шулай дәвалануын искә ала.

**(Дәвамы бар)**

***Фәния ХУҖАХМӘТ.***
***(«Һәр авыруга дәва бар» китабыннан)***

## Внимание!

16 июня в Самарской Соборной мечети состоится областная викторина для детей школьного возраста «Знаешь ли ты Ислам!». Начало - в 10:00.

Просим подготовить команду от вашего района не менее 5 человек и подать заявку до 1 июня по адресу: г. Самара, ул. Стара Загора, 54 (Самарская Соборная мечеть).

**Конкурсы викторины**

1. Сценка на какую-либо историю Ислама.
2. Один мунажат (исполняют муж. пол или девочки до 9 лет) и стих.
3. Чтение Корана наизусть от «Филь» до «Нас».
4. Вопросы и ответы об Исламе.
5. Вопросы и ответы между командами.
6. Кроссворды.

**Командам нужно подготовить домашнее задание:**

1. Сценку на какую-либо историю Ислама.
2. Один мунажат (исполняют муж. пол или девочки до 9 лет).
3. Чтение Корана наизусть от «Филь» до «Нас».

**Тел. организаторов: 8 927 023 96 72 , 8 927 694 93 32.**

В здании Самарской Соборной мечети каждую субботу с 10 до 13 часов проводится бесплатная юридическая консультация по гражданско-правовым вопросам.

**РДУМСО.ы**

**ОБЪЯВЛЕНИЕ**

Начался набор на новый 2012-2013 учебный год

**ПРИГЛАШАЕМ ВСЕХ ЖЕЛАЮЩИХ ПОСТУПИТЬ НА УЧЕБУ В МЕДРЕСЕ «НУР» (Г. САМАРА)**

**УСЛОВИЯ ПРИЕМА В МЕДРЕСЕ «НУР»**

В медресе принимаются граждане Российской Федерации мужского пола мусульманского вероисповедания в возрасте до 35 лет (на очное, вечернее обучение), имеющие светское основное общее, среднее (полное) общее или профессиональное образование.

**ДОКУМЕНТЫ, НЕОБХОДИМЫЕ ДЛЯ ПОСТУПЛЕНИЯ**

- договор;
- личное заявление на имя ректора медресе;
- свидетельство о рождении;
- паспорт (документ удостоверяющий личность);
- документ государственного образца об образовании;
- письменная рекомендация имама, заверенная председателем махалли;
- анкета;
- автобиография;
- военный билет или приписное свидетельство;
- характеристика;
- справка о составе семьи;
- медицинская справка установленной формы (ф.О86);
- фотокарточки 3х4 (6 шт.);
- для женатых — свидетельство о браке.

Документы подаются в приемную комиссию по адресу: 443081, г. Самара, ул. Стара-Загора, д. 54 не позднее 25 августа.

Телефоны для справок: **8 (846) 951-84-46 +7-927-023-96-72; +7-927-694-93-32**

E-mail: **medresenur@mail.ru**

# Мулла Гата язмышы

**(Ахыры. Башы 3нче биттә)**

Минем инәй Җәмилә һәм әтием Гилинең бөтен баласы да югары белем алып мәктәптә эшләделәр. Инәйнең васыяте буенча без барыбыз да намаз укучылар булдык һәм балаларыбызны да дин юлында тәрбияләргә тырышабыз. Гата бабайның балалары үзләренең әти-әниләренә догачылар булып, төрле төбәкләрдә сибелеп яшиләр.

**Редакциядән:** Революциядән соңгы шаукымлы елларда һәм аннан соң да күп кенә муллаларны, дин әһелләрен җәберләп, төрмәләргә ябып, гаиләләре белән сөргенгә сөреп, атып, төрлечә җәзалап, зинданнарда интектереп харап иттеләр. Аларның фаҗигалы язмышлары турындагы күп кенә мәгълүматлар инде эзсез югалган, ә күбесе турындагы хәбәрләрне җыеп, алар истәлеген саклап калырга әле мөмкинлекләр бар. Бу - җәмгыятебезнең изге бурычы. Дин әһелләренең күбесе чиксез кысрыклауларга, рәнҗетүләргә түзә алмыйча, муллалыктан ваз кичкәннәр. Ә кайберәүләр төрмәдә утырып чыккач та үз эшен дәвам иткәннәр. Алар киләчәктә халык динле, тәрбияле булсын өчен көрәшкәннәр. Без алар турындагы якты истәлекләрне җыеп тупларга һәм сакларга тиешбез. Бу турыда сездән хәбәрләр көтәбез.

***Нәзимә БАШАРОВА.***

# Игътибар!

## 23 июньдә Самарның Гагарин исемендәге паркында өлкә Сабан туе уздырыла.

Быелгы Сабан туе бәйрәменең девизы - «Һәр татар “Бердәмлек”кә языла!».

## Программада:

- Татарстанның Зәй районы артистлары концерты;
- Камышлы, Гали, Мәчәләй, Чаллы Баш авылларының үзешчән сәнгать коллективлары чыгышы;
- Сызран, Нефтегорск, Җигули, Тольятти шәһәрләре үзешчәннәре җырлый;
- “Яктылык” мәктәбе үзенең бию төркемнәре белән катнаша;
- “Ялкынлы яшьлек” исемле җыр, бию, шигърият ансамбле Сабан туе концертын түгәрәкләячәк.
- татарча көрәш сәгать унда башлана;
- татар халык ризыкларын, татар дискларын, татар китапларын, дини әдәбиятны сатып алу мөмкинлеге дә бар;
- гер күтәрү, аркан тарту, баганага менү, кул көрәше, капчык сугышы һәм башка бик күп уеннарда, конкурсларда катнаша аласыз.

Көне буена җыр, бию, күңел ачулар.

“Бердәмлек” гәҗитәсенә язылу оештырыла.

## Бәйрәмне оештыручылар:

- “Туган тел” исемле Самар өлкә татар җәмгыяте;
- өлкә татар милли-мәдәни мохтарияте;
- Самар шәһәре татар милли-мәдәни мохтарияте;
- өлкә Халыклар дуслыгы йорты.

Сабан туйга матди ярдәм күрсәтүчеләр:

- өлкә хөкүмәте;
- Самар шәһәр мэриясе;
- эшбатырларыбыз.

**Сабан туй сәгать унда башлана.**

Ял итәргә рәхим итегез !

***Шамил БАҺАУТДИН.***

## Объявление

Самарской Исторической мечети (ул. А. Толстого, 61) требуются дежурные мечети - 2 человека.

**Т.: 340-74-66.**

**Администрация.**

***Уважаемые читатели!***

***В газете упоминаются имена Всевышнего и Его Пророка, публикуются аяты из Корана, высказывания Пророка и молитвы. Поэтому просим Вас относиться к газете уважительно, не использовать ее в недостойных целях.***

***Точка зрения авторов может не совпадать с мнением редакции.***

**УЧРЕДИТЕЛИ:** Региональное Духовное управление мусульман Самарской области и местная мусульманская религиозная организация Самарская Соборная мечеть.
**АДРЕС РЕДАКЦИИ И ИЗДАТЕЛЯ:** 443081, г. Самара, ул. Стара Загора, 54. Соборная мечеть. Телефон: 932-58-67. Электронный адрес: islam-nur@bk.ru

**Редактор** - Фарид ШИРИЯЗДАНОВ.
**Корреспондент** - Али СУЛЕЙМАНОВ.
**Ответственные за выпуск газеты:**
**по организационно-финансовым вопросам** - Джавдят ШАРАПОВ,
**по духовно-просветительской части** - Наиль СУЛЕЙМАНОВ.
**Набор и верстка** - Рамиль НУРЕТДИНОВ.
**Корректор** - Миляуша ГАЗИМОВА.

**Время подписания к печати:**
***по установленному графику - 4 июня 9.00,***
***фактически - 4 июня 9.00.***

**Отпечатано в ОАО «Типография «Солдат Отечества»**
**Адрес: г. Самара, ул. Авроры, 112 Б.**
**Заказ 732 Тираж 2000.**
***Цена свободная.***
Рег. свидетельство ПИ № ТУ63-00111